Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Поповка авыл жирлегенең Поповка торак пунктында
гражданнар жыены нәтижәләре турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 02 нче нояберендә булып узган гражданнар жыены нәтижәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл жирлегенең Поповка торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә һәм жыелган акчаларны түбәндәге жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Православие зиратына кадәр авылга вак таш жәю».

Гражданнар жыены нәтижәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 55 кеше кертелгән, жыенында 38 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар жыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе буенча гражданнар жыенында катнашучыларның 36 кеше тавыш бирде;

"Каршы" дип 2 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар жыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл жирлегенең Поповка торак пунктында гражданнар жыены үткән, гражданнар жыенының нәтижәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл жирлегенең Поповка торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 сумм күләмендә билгеләргә һәм жыелган акчаларны түбәндәге жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Православие зиратына кадәр авылга вак таш жәю» - дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар жыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге башлыгына жибәрергә.

**Гражданнар жыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Поповка авыл җирлеге башлыгы** **И.А. Амерханов**